

ЖИР ЙӨЗЕНДӘ ТЫНЫЧЛЫК ,ДУСЛЫК, МӘРХӘМӘТЛЕЛЕК, ГАДЕЛЛЕК БУЛСЫН!

№1 Сентябрь Октябрь

2021 нче ел

# МӘКТӘП СУЛЫШЫ

## *Октябрь ае бәйрәмнәре.*

1 нче октябрь - **Өлкәннәр көне**. Шул уңайдан мәктәбебездә бу көннәрдә бик күп чаралар узды: игелек акциясе, тимурчылык эше. Һәр сыйныф укучылары өлкәннәрне бәйрәм белән котлап, үз куллары белән ясаган бүләкләр тапшырдылар.

Без өлкәннәребезгә сәламәтлек, күңел тынычлыгы телибез.







**Яраткан укытучыларыбыз!**

Ихластан һөнәри бәйрәмегез - Укытучылар көне белән котлыйбыз! Сәламәтлек, сабырлык, иҗади уңышлар телибез.

Һөнәрләр күп:кем булсаң да
Табиб,эшче, тукучы...
Тик онытма бер нәрсәне-
Юл күрсәтә укытучы!

Юл күрсәтүчеләребез - укытучыларыбыз - без Сезне бик яратабыз, хөрмәт итәбез!



## Бу санда

***Октябрь ае бәйрәмнәре***



**“Сәйяр” балалар һәм яшүсмерләр республика театр фестивале**



***Марсель Галиевка 75 яшь***



# “Сәйяр” балалар һәм яшүсмерләр республика театр фестивале





11 октябрь көнне «Сәйяр» Республика балалар һәм яшүсмерләр театр фестиваленең муниципаль туры узды. Мәктәбебезнең “Ямьле балачак” театр коллективы Абдулла Әхмәтнең "Үги кыз" әсәрен күрсәтте. Укучыларыбызның чыгышы икенче урынга лаек булды. Яшь артистларыбызга алга таба да иҗади уңышлар телибез.



**Тәмле булсын**

***Бүген бәйрәм табынына кыстыбый әзерлибез. Кыстыбый** – татар халкының табын күрке булган милли ризыкларының берсе.*

**Кыстыбый:**
**Камыр ясау өчен:** 1 йомырка, 1 стакан сөт яки су, 50 грамм атланмай, бер бал кашыгы тоз, 1 аш кашыгы майонез, он

**Эчлеге өчен:** 1 кг бәрәңге, 1 стакан сөт, 50 гр атланмай, 1 суган, тоз, борыч





Бәрәңгене тозлы суда пешереп сөзәбез. Кайнар сөт, атланмай, тоз, борыч салып төябез. Кыздырып суган салабыз. Эчлекне тастымал белән төреп куябыз.Төче камыр әзерлибез. Савытка йомырка, сөт яки су, атланмай, тоз салып болгатабыз, бераз майонез салсаң йомшаграк була. Аннан он өстәп кулга ябышмый башлаганчы камыр басабыз.

Камырны берничә кисәккә бүлеп, юка итеп җәябез. Җәемнәрне майланган табада пешереп алабыз. Аларның яртысына җылы эчлекне ягып икенче ягы белән каплыйбыз. Кыстыбыйны эрегән сыер мае белән майлыйбыз. Табынга җылы килеш чыгарабыз.





***Бәйрәм сыебыз әзер! Ашларыгыз тәмле булсын!***



# Татарстанның халык язучысы Марсель Галиевка 75 яшь

*Бүген бездә кунакта*



**Марсель Галиев** — татар шагыйре, язучы, Г. Тукай исемендәге Татарстан дәүләт премиясе лауреаты. Татарстанның халык язучысы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

Ул 1946 елның 8 октябрь көнендә Азнакай районы Балтач авылында туган. Үз районындагы татар урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, берникадәр вакыт төзү–монтаж идарәсендә эшли. 1969 елда Марсель Галиев Казан дәүләт университетының журналистика бүлегенә укырга керә; 1974 елдан 1983 елга кадәр Татарстан Язучылар берләшмәсендә әдәбиятны пропагандалау бюросында әдәби хезмәткәр һәм «Казан утлары» журналы редакциясендә проза бүлеге редакторы булып эшли.

Марсель Галиев шигърият һәм проза жанрында иҗат итә. Матбугатта аның әсәрләре 70нче еллар башында күренә башлый. 1979 елда «Еллар чалымы» исеме белән мөстәкыйль шигырьләр җыентыгы, ә 1980 елда ике повестен эченә алган «Ул чакта» исемле проза китабы дөнья күрә.

20 нче октябрь көнне мәктәбебездә М. Галиевның 75 яшенә багышланган чара үтте. Укучылар язучының хикәяләрен искә төшерделәр, “Җиңәсем килде” әсәренә аерым тукталдылар.








# “Татарча диктант” акциясе

10 сентябрь көнне  бөтен дөнья “Татарча диктант” акциясендә катнашты. Акциянең максаты – татар телендә хатасыз язарга өйрәтү, әдәби татар телен кулланучыларның даирәсен арттыру, орфографик һәм грамматик хаталарны тикшерү. Һәр теләгән кеше, диктант язуда катнашып, татар телен белү дәрәҗәсен тикшереп карый алды. Әлеге акциягә 2нче санлы Урыссу урта гомуми белем бирү мәктәбе дә кушылды. Диктант язучылар арасында дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр, укучылар, тәрбиячеләр, пенсионерлар да бар иде.

Әлеге проектта безнең мәктәп укучылары, ата-аналар, укытучылар да актив катнашты.








## *Ә син белә идеңме?*



# *Хәситә*

Татар хатын-кызлары муен-күкрәк бизәнү әйберләрен иркен кулланганнар. Алар бизәнү әйбере генә түгел, киемнең бер өлеше булып торган. Шулай ук, иң киң таралган бизәнү әйбере булып хәситә санала. Хәзерге заманда бу сүз кулланылыштан төшеп калса да, аны икенче атама белән-муенса дип атап йөртәләр.

Хәситә-озынлыгы 30-40 см, киңлеге 5-12 см булган тукыма бәйләвеч. Аны күлмәк өстеннән сул беләк аша үткәреп, уң култык астына кигәннәр. Хәситә тукымасына коръән салганнар. Хәситәгә төрле тәңкәләр, асылмалар, кыйммәтле ташлар һәм йомры сәдәфләр тагылган. Аларны хәситәнең бөтен буена рәт-рәт итеп тезгәннәр. Бишәр-алтышар тезмәле хәситәләр аеруча затлы күренгән.

Тукыма хәситәләрдән тыш, бай шәһәр хатыннарының коелган яисә сәркә тәңкәләрдән ялгап эшләнгән тоташ метал хәситәләре киюе дә билгеле. Аларына төсле ташлар белән бизәлгән асылмалы тәңкәләр тагылган.





**Гәҗитне басмага әзерләделәр:**

7 нче сыйныф укучылары

Җитәкчеләре: Хөсәенова Л.Т.

***Сездән язмалар көтеп калабыз!***